**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7349**
**14.08.2023**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә тарифны раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 3571 номерлы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә тарифны раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 3571 номерлы карарының 1 пунктына, «329 (өч йөз егерме тугыз) сум 72 тиен күләмендә» сүзләрен «515 (биш йөз унбиш) сум 94 тиен күләмендә» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов